Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Куакбаш авыл җирлегенең
Чүте авылы гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Чүте авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Чүте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (Бер мең) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:
2.1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Чуте авылында (Гагарин урамы, Тынычлык урамы)юлларны кардан чистарту

2.2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә су чыгаруны оештыру:

Чуте авылы каптажын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 61 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 38.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 38 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Чүте авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Чүте авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Чүте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (Бер мең) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:
2.1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл

эшчәнлеге:

Чуте авылында (Гагарин урамы, Тынычлык урамы)юлларны кардан чистарту

2.2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә су чыгаруны оештыру:

Чуте авылы каптажын ремонтлау сораулары буенча карарны кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Сходнево-Чертанла, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Чүте авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова